РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МОКРОСАВАЛЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӨКЕРЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«29» май 2025 ел № 17

Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 05 февралендәге 124 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 10 августындагы 20 номерлы карары белән расланган Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктында.:

бишенче абзацта «әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән» сүзләрен «гаризасы белән» сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. 1.5. пунктында:

сигезенче абзацта «(шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы),» сүзләреннән соң «яр буе,» сүзен өстәргә.;

тугызынчы абзацта «яр буе» сүзен төшереп калдырырга.

1.3. 2.3.пункты:

Түбәндәге эчтәлекле 2.3.6 пунктчасы өстәргә;

«2.3.6. Объектына адрес бирү яисә аның адресын юкка чыгару турында карар, адреслашу объектына адрес бирүдән баш тарту яисә аның адресын юкка чыгару турында карар кабул итү, шулай ук адреслашу объектының адресы турында тиешле белешмәләр урнаштыру дәүләт адреслар реестрында вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

а) гариза кәгазьдә бирелгән очракта - гариза кергән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча;

б) электрон документ рәвешендә гариза биргән очракта - гариза кергән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча.".

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккач законлы көченә керә (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш (http://buinsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Мөкерле авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе С.Н. Тюплина